| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.10.2022 Олы Кайбыч ав. № 448

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 февралендәге 64 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны кайнар туклandыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында», 2022елның 03 октябрендәге 1065 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 сентябрендәге 991 номерлы «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны кайнар туклandыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарлары нигезендә һәм аерым категория укучыларга социаль ярдәм буенча өстәмә чараларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Бшкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 февралендәге 64 номерлы карарына (2021 елның 01 декабрендәге 480 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җиденче юлны өстәргә:

«- өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары.».

1.2. 2 пунктта:

2.4. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны көнгә бер укучыга 58 (илле сигез) сум 94 тиенгә түләүсез кайнар азык белән тәэмин итәргә.»;

2.5. пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны 8 сум 80 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-ана түләвеннән (законлы вәкилдән) торган суммага ашатуны оештырырга.».

2. Әлеге карарның 1.1 пунктындагы 1 пунктчасының гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән гражданның өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәт узу вакытына барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктының 1.2 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина